**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Якты Күл авыл җирлеге Советы**
**К А Р А Р Ы**

**30.09.2022 ел.** **№ 71**

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Якты Күл җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 100 номерлы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы закон), Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Якты Күл җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 100 номерлы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 29 маендагы 103 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 126 номерлы, 2018 елның 07 декабрендәге 129 номерлы, 2020 елның 22 сентябрендәге 05 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 43 номерлы карарлар нигезендә кертелгән өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Якты Күл җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктында «11498 сум» сүзләрен «11958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Зәй муниципаль районы Якты Күл җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы

вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2 кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә:
“Якты Күл авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме”;

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 16389 |

1.3. Зәй муниципаль районы Якты Күл җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.14 пунктында «11498 сум» сүзләрен «11958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**Якты Күл авыл җирлеге башлыгы** **З. З. Мөхтәров**